**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 22 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Иске Куак авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, бала чактан инвалидлар, I, II төркем инвалидлар, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, мобилизацияләнгән гражданнар, контракт буенча хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Иске Куак авылындагы яңа зиратта киртәләр кору).

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Куак авылында, Совет урамы буенча юлдагы чокырларны вак таш җәеп ремонтлау).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Кувак авыл җирлеге территориясендә үлән чабу).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин ур., 36 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Иске Куак авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сушкова